СОВЕТ ТАТАРСКО ДЮМ-ДЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ДӨМ-ДӨМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.10.2024 с.Татарский Дюм-Дюм № 28

Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»24.07.2024 елның 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советы

Карар кылдым:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советының 23.07.2024 №23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5.9 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Профилактик визитны үткәрү срогы 10 эш көне тәшкил итә, ләкин инструменталь тикшерү өчен кирәкле вакытка озайтылырга мөмкин, ләкин ул 4 эш көненнән дә артмаска тиеш. Берничә зат файдалана яисә идарә итә торган объектларда профилактик визит уздырган очракта профилактик визитны уздыру вакыты 10 эш көненнән дә артмаска мөмкин.».

1.2. 4.6.8 пунктта «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә»сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 4.8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.9.1 пунктының 1 пунктчаларында каралган карарлар кабул ителә алмый.».

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис И.Н. Хәбибуллин